ГЛАВА
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.02.2019 Алексеевск ш.т.б. № 14

**Алексеевск муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен (гражданнар оборонасы хезмәтләрен) төзү турында» 2018 елның 12 гыйнварындагы 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 26 ноябрендәге 80 номерлы РФ Хөкүмәте Карары нигезләмәләренә туры китерү максатында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен (гражданнар оборонасы хезмәтләрен) төзү турында» 2010 елның 15 гыйнварындагы 6 номерлы карары нигезендә (12.02.2018 елгы үзгәрешләр белән), шулай ук кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә

**карар бирәм:**

Алексеевск муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен (гражданнар оборонасы хезмәтләрен) төзү турында» 2018 елның 12 гыйнварындагы 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- **1 нче кушымтада** «Алексеевск муниципаль районының гражданнар оборонасы хезмәтләре исемлеге»

«Гражданнар оборонасы хезмәте җитәкчесе» дигән баганада

«Россия Эчке эшләр министрлыгының Алексеевск районы буенча бүлеге башлыгы Мораткин Иосиф Виссарион улы 884341 2- 53-35 89997580119» сүзләрен

«Россия Эчке эшләр министрлыгының Алексеевск районы буенча бүлеге башлыгы Яковлев Вячеслав Анатолий улы 884341 2-53-35, 89997580120» сүзләренә алмаштырырга;

«Генераль директор урынбасары Саттаров Марат Дамир улы» сүзләрен «Генераль директор Саттаров Марат Дамир улы» сүзләренә алмаштырырга;

«Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Сергеева Татьяна Николай кызы 884341 2-53-66 89272485085» сүзләрен «Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Васильев Алексей Дмитрий улы 884341 2-53-66, 9872977895» сүзләренә алмаштырырга;

«Хезмәт штабы башлыгы – гражданнар оборонасы хезмәте җитәкчесе урынбасары» дигән баганада

«Башкарма комитетның икътисад бүлеге башлыгы Михайлова Лилия Василий кызы 84341 2-37-62, 89178782174» сүзләрен «Башкарма комитетның икътисад бүлеге башлыгы Сергеева Татьяна Николай кызы 84341 2-37-94, 89272485085» сүзләренә алмаштырырга;

- **2 нче кушымтада** «Алексеевск муниципаль районында коткару хезмәтләрен (гражданнар оборонасы хезмәтләрен) формалаштыру һәм аларның эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибе»

**1 бүлектәге 1 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Коткару хезмәте (гражданнар оборонасы хезмәте) (алга таба - Гражданнар оборонасы хезмәте) – ул гражданнар оборонасы буенча билгеләнгән чараларны үткәрү, авария-коткару формированиеләренең эшчәнлеген һәрьяклап тәэмин итү һәм хәрби конфликтлар вакытында яки әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән башка кичектергесез эшләрне башкару, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр һәм террорчылык актлары вакытында билгеләнгән чараларны үткәрүче идарә органнары, гражданнар оборонасы көчләре һәм чаралары җыелмасы.»;

**3 бүлегендәге 1 пунктның 5 абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр барышында гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәлешен тәэмин итү буенча штаттан тыш авария-коткару формированиеләренең һәм штаттан тыш формированиеләренең гамәлләрен тәэмин итүне оештыру»;

**3 бүлекнең 2.4 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2.4. Янгынга каршы хезмәт:

янгынга каршы көч булдыру, аларны җиһазлау һәм гражданнар оборонасы өлкәсендә әзерләү;

сугыш вакытында авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр үткәрү урыннарында янгын сүндерүне оештыру;

сугыш вакытында торак төзелеше урыннарында янгын сүндерүне оештыру.

**3 бүлекнең 2.5 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Транспорт белән тәэмин итү һәм ягулык-майлау материаллары белән тәэмин итү хезмәте:

шәһәрләрдән эвакуацияләнә торган халыкны кабул итү пунктларыннан алып урнашу урыннарына кадәр озатуны тәэмин итүне оештыру, зарарланган урыннарда, гадәттән тыш хәлләр булган урыннарда авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр үткәрү өчен гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын, саклагыч корылмалар төзү өчен материаллар белән тәэмин итүне оештыру;

гражданнар оборонасы чараларын үтәү барышында сафтан чыккан автомобиль техникасын ремонтлауны оештыру;

автомобиль техникасын махсус эшкәртү өчен көч булдыру һәм җиһазландыруны оештыру;

ягулык-майлау материаллары белән тәэмин итү.

штаттан тыш авария-коткару формированиеләренең автомобиль, инженер һәм махсус техникасын, гражданнар оборонасы буенча чаралар үткәрүгә җәлеп ителә торган штаттан тыш формированиеләрнең эвакуация чараларын үткәрүгә җәлеп ителә торган автомобиль техникасын, шул максатта стационар һәм күчмә автозаправка станцияләрен файдалану юлы белән, ягулык-майлау материаллары белән тәэмин итү буенча чаралар оештыру һәм үткәрү»;

**3 бүлектәге 2.10 пунктының 5 абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр үткәрү урыннарында гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәлешен тәэмин итүче штаттан тыш авария-коткару формированиеләренең, штаттан тыш формированиеләренең шәхси составын туклану белән тәэмин итүне оештыру.»;

**5 бүлекнең 1 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнар оборонасы хезмәтләре белән идарә итү тиешле хезмәт җитәкчеләре һәм аларның идарә органнары карамагындагы штаблар ягыннан тыныч вакытта һәм сугыш вакытларында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү буенча әзерлекне тәэмин итү, эшчәнлекне оештыру буенча штаттан тыш авария-коткару формированиеләре, штаттан тыш формированиеләр тарафыннан гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәлешен тәэмин итү эшенә даими җитәкчелек итүдән гыйбарәт.»;

**5 бүлекнең 6 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«6. Гражданнар оборонасы чараларын һәрьяклап тәэмин итү өчен гражданнар оборонасы хезмәтләре:

гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәлешен тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләр, хезмәт эшчәнлегенең профиленә туры килә

торган авария-коткару формированиеләрен җәлеп итәләр;

гражданнар оборонасы бурычларын хәл итү өчен җәлеп ителә торган хезмәтләр һәм оешмалар составына керүче формированиеләрне исәпкә алуны оештыралар.

Гражданнар оборонасы хезмәтләре тарафыннан җәлеп ителә торган гражданнар оборонасы чаралары үтәлешен тәэмин итүче авария-коткару формированиеләренең һәм штаттан тыш формированиеләренең гомуми күләме һәм аларның тыныч вакытта һәм сугыш вакытында хәл итә торган бурычларының характеры һәм күләме җирле шартлар үзенчәлекләрен исәпкә алып, кеше ресурслары һәм матди чаралар булу белән билгеләнә.

Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының штаттан тыш авария-коткару формированиеләрен булдыру, комплектлау, исәпкә алу тәртибе һәм аларның оештыру-штат структурасы «Алексеевск муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының муниципаль звеносы турында» 2018 елның 17 маендагы 127 номерлы карары белән билгеләнгән.

- 4 нче кушымтада «Алексеевск муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү турында Нигезләмә»

**4 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Гражданнар оборонасы өлкәсендә халыкны укыту белән бәйле бурычларны хәл итү максатларында гамәлгә ашырыла торган төп чаралар булып тора:

халыкны гражданар оборонасы өлкәсендә әзерләү эшен Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча укыту-методик үзәгенең Чистай шәһәрендәге филиалында үткәрүне планлаштыру һәм тормышка ашыру;

гражданнар оборонасы өлкәсендәге оешмаларның хезмәткәрләрен әзерләү өчен укыту-матди база булдыру һәм аларны эш халәтендә тоту;

оешмаларда гражданнар оборонасы өлкәсенең консультатив пунктларын булдыру һәм аларны эш халәтендә тоту;

гражданнар оборонасы өлкәсендә белемнәрне пропагандалау. Күрсәтелгән чараларны үтәүне оештыру Алексеевск янгын саклау гарнизонына йөкләнә.»;

**5 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.Гражданнар оборонасы буенча төп чаралар булып, халыкны хәрби конфликтлар вакытында яки әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә барлыкка килә торган куркынычлыклар турында хәбәр итү белән бәйле бурычларны хәл итү максатларында гамәлгә ашырыла торган төп чаралар булып тора:

халыкка үзәкләштерелгән хәбәр итү системасын булдыру һәм аны даими

әзерлек хәлендә тоту, яңа буын техник чаралар базасында модернизацияләүне гамәлгә ашыру, хәбәр итү системасын камилләштерү, Россия Федерациясе электр элемтәсе бердәм челтәре, «Таттелеком» ДУП чараларын комплекслы куллану һәм мәгълүмат тапшыруның башка техник чараларын куллану.

Әлеге чараны үткәрүне оештыру Чистай зонасы электр элемтәсе узелының район электр элемтәсе узелына йөкләнә;

район халкын матбугат чаралары аша гражданнар оборонасы буенча чараларның үтәлеше турында мәгълүмат белән тәэмин итү.

күрсәтелгән чараның үтәлешен оештыру «Татмедия» ААҖнең Алексеевск филиалы булган «Таң» газетасы редакциясенә йөкләнә;

халыкны почта элемтәсе белән тәэмин итү. Күрсәтелгән чараның үтәлешен оештыру "Россия Почтасы" дәүләт унитар предприятиесенең Чистай МРП УФПС "Татарстан Почтасы" филиалы Алексеевск РУПСына йөкләнә";

Гражданнар оборонасы өлкәсендә мәгълүмат җыю һәм алмашу. Әлеге чараның үтәлешен оештыру Алексеевск янгын саклау гарнизонына йөкләнә;

куркыныч матдәләр чыгаруны һәм халыкка үзәкләштерелгән хәбәр итүне контрольдә тотуның автоматлаштырылган системалары белән бәйле рәвештә потенциаль куркыныч объектларда һәм аларны урнаштыру районнарында локаль хәбәр итү системаларын булдыру. Әлеге чараның үтәлешен оештыру үз составында потенциаль куркыныч объектлары булган оешмаларга йөкләнә;

кешеләр күпләп җыела торган урыннарда халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирүнең махсуслаштырылган техник чараларын урнаштыру. Әлеге чараның үтәлешен оештыру килешү нигезендә Чистай зонасы электр элемтәсе узелының район электр элемтәсе узелына, Алексеевск янгын саклау гарнизонына йөкләнә.»;

**6 пунктның 5 абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эвакуацияләнергә тиешле халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне саклау урыннарын урнаштыру өчен куркынычсыз районнар әзерләү. Күрсәтелгән чараларны үтәүне оештыру законнарда билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында җирле үзидарә органнарына йөкләнә;»;

**7 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.Халыкка радиациядән саклану корылмалары һәм шәхси саклану чаралары бирү белән бәйле бурычларны хәл итү максатларында гамәлгә ашырыла торган гражданнар оборонасы буенча төп чаралар булып тора:

гражданнар оборонасының гамәлдәге саклау корылмаларын һәм тормыш иминлеген тәэмин итү системаларын төзү, билгеләнгәнчә куллану өчен даими әзерлек хәлендә тоту, эксплутацион-техник хезмәт күрсәтү һәм модернизацияләү;

күмелеп ясалган биналарны һәм җир астындагы башка корылмаларны тыныч вакытта һәм тыныч вакыттан сугыш вакытына күчергәндә халыкны

яшерер өчен җайлаштыру;

тыныч вакытта, гражданнар оборонасын алып барганда, хәрби вакытта кулланырга әзер торган, гражданнар оборонасының гади генә типтагы эчке җиһазлары һәм яшеренү урыннары булган саклау корылмаларында халыкны яшерүне тәэмин итүче, гражданнар оборонасының тиз төзелә торган саклау корылмаларын төзү.

Күрсәтелгән чараларны үтәүне оештыру Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә йөкләнә;

халыкка шәхси саклану чараларын һәм коллектив саклау чараларын билгеләнгән вакытта бирүне тәэмин итү.

халыкның шәхси саклану чараларын туплау, саклау, яңарту, билгеләнгәнчә куллану һәм билгеләнгән срокларда бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә күмәк яклау чаралары бирүне Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты гамәлгә ашыра, оешма хезмәткәрләренә һәм аларның гаилә әгъзаларына – оешма җитәкчеләре, федераль дәрәҗәдәге оешмаларның эшчеләренә һәм гаилә әгъзаларына – федераль оешма җитәкчеләре, эшләми торган халыкка, укучыларга, балаларга – Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы бирә;»;

**9 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.Хәрби конфликтлар яисә әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә халык өчен куркыныч барлыкка килгән очракта, авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр үткәрүгә бәйле мәсьәләләрне хәл итү максатларында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр һәм террорчылык актлары вакытында гамәлгә ашырыла торган гражданнар оборонасы буенча төп чаралар булып тора:

Гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итү өчен җәлеп ителә торган штаттан тыш авария-коткару формированиеләренең һәм гражданнар оборонасы буенча региональ дәрәҗәдәге чаралар үтәлешен тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләренең реестрларын исәпкә алу һәм алып бару.

Гражданнар оборонасы авария-коткару формированиеләрен, гражданнар оборонасы чараларын һәм коткару хезмәтләрен (гражданнар оборонасы хезмәтләрен) үтәүне тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләрне булдыру, җиһазлау һәм әзерләү, шулай ук аларның гамәлләрен планлаштыру;

авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне һәрьяклап тәэмин итү өчен матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын билгеләү буенча даими әзерлектә булу һәм ярдәм итү

авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне үткәрүнең заманча технологияләрен һәм техник чараларын эшләү.

Күрсәтелгән чараларны үтәүне оештыру законнарда билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында муниципаль берәмлеккә һәм оешмаларга йөкләнә;

Гражданнар оборонасы көчләренең Россия Федерациясенең Кораллы Көчләре, башка гаскәрләре, хәрби формированиеләр һәм органнар белән, шулай ук хәрби вакытта төзелә торган махсус формированиеләр белән үзара хезмәттәшлеген оештыру.»;

**10 пунктның 1 абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнар оборонасы буенча төп чаралар булып хәрби конфликтлар вакытында яисә әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә зыян күргән халыкның, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргәннәрнең тормыш эшчәнлеген беренчел тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла торган бурычлар тора:»;

**10 пунктның 8 абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хәрби конфликтлар вакытында яки әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән халык арасында санитар-гигиена һәм эпидемиягә каршы чаралар үткәрү; Әлеге чараның үтәлешен оештыру «Роспотребнадзор»ның ТР буенча идарәсенең Чистай районы һәм Чистай шәһәрендәге территориаль бүлегенә, «Татарстан Республикасында гигиена һәм эпидемиология үзәге» Алексеевск филиалына йөкләнә;»;

**11 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11.Хәрби конфликтлар вакытында яки әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән янгыннар белән көрәш бурычларын хәл итү максатларында гамәлгә ашырыла торган гражданнар оборонасы буенча төп чаралар булып тора:

янгынга каршы көч булдыру, аларны җиһазлау һәм гражданнар оборонасы өлкәсендә әзерлек;

хәрби вакытта авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр үткәрү районнарында янгын сүндерүне оештыру;

хәрби вакытта торак төзелешендәге янгыннарны сүндерүне оештыру. Күрсәтелгән чараларны үтәүне оештыру «ТР буенча 7 федераль янгынга каршы хезмәт отряды» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең 104 номерлы янгыннан коткару бүлекчәсенә йөкләнә.

**14 пунктның 1 абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14.Хәрби конфликтлар вакытында яки әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә зыян күргән районнарда тәртипне торгызу һәм саклау, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр һәм террорчылык актлары һәм террорчылык актлары вакытында саклану мәсьәләләрен хәл итү максатларында гамәлгә ашырыла торган гражданнар оборонасы буенча төп чаралар булып тора:»;

**17 пунктның 1 абзацын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Хәрби конфликтлар вакытында яки әлеге конфликтлар нәтиҗәсендә,

шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә халыкның иминлеген тәэмин итүче оешмаларның тотрыклы эшләвен тәэмин итүгә бәйле бурычларны хәл итү максатларында гамәлгә ашырыла торган гражданнар оборонасы буенча төп чаралар:»;

**18 пунктның 3** абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнар оборонасы һәм коткару хезмәтләре (гражданнар оборонасы хезмәтләре) чараларын үтәүне тәэмин итү буенча эш урыннарында авария-коткару формированиеләренең шәхси составы, штаттан тыш формированиеләр белән дәресләр үткәрү, гражданнар оборонасы буенча өйрәнүләр һәм тренировкалар үткәрү. Күрсәтелгән чараларны үтәүне оештыру гражданнар оборонасы хезмәтләре, шулай ук законнар белән билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында җирле үзидарә органнары тарафыннан оештырылган оешмалар җитәкчеләренә йөкләнә; ».

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитеты җитәкчесе – Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы гражданнар оборонасы җитәкчесе урынбасары Н.К. Кадыровка йөкләргә.

**Муниципаль район башлыгы** **С.А. Демидов**